ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.02.2022**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 329**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 10 декабрендәге 2826 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160[1] статьясының 3[2] пункты дүртенче абзацы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 10 декабрендәге «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2826 номерлы карары белән расланган 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 27 гыйнварындагы 134 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)(алга тата-Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. Исемлеккә түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «802 | 1 11 09080 05 0000 120 | Муниципаль районнар милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә, реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә хокук бирү өчен килешү кысаларында кергән түләү» |

2. Әлеге карарның гамәлен 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — И.Р. Ганиев